## СЕЗНЕҢ ХОКУКЛАРТУРЫНДА АҢЛАТМА БИРҮ

**СЕЗНЕ КУЛГА АЛМЫЙЧА**шикләнелүче сыйфатында сораштыру вакытта



### 1. Адвокат белән яшерен консультациягә хокук һәм сорау алу барганда юридик ярдәм

A. Кайчан?

- Сезнең беренче сорау алганга кадәр адвокат белән яшерен консультациягә һәм сорау алу барганда юридик ярдәмгә хокукыгыз бар.
- Җәза ирректән мәхрүм итүне күздә тотса, Сездән җинаять турында сорау алган очракта, С.пунктында язылганнарга таянырга.

B. Нинди адвокат?

- Сез үзегез сайлаган адвокат белән киңәшләшә аласыз.
- Билгеләнгән хокук шартларында Сез тулысынча яки өлешчә бушлай булган юридик консультация системасы аша адвокат чакыра аласыз. Сез бу шартларны кыскача формалаштырган форманы сората аласыз. Шуннан соң Сез адвокат лар Берләшмәсенең Хокук Ярдәм Бюросыннан яклаучы билгеләүне сорарсыз.

C. Яшерен консультация ничек үткәреләчәк?

Әгәр сезгә 1-4 пунктлары астында билгеләнгән язма чакыру кабул итсәгез, бу Сез сорау алуга кадәр адвокат белән консультацияне инде үткәргәнегезне күзтә тота:

- Сезгә кичектерү мөмкинлеген бүтән бирмиячәкләр, чөнки сезнең адвокат белән консультация үткәрер өчен вакытыгыз бар иде.
- Әгәр Сез адвокат ярдәмен сорамасагыз, Сезгә сорау алу башланганчы тынлык сакларга киңәш ителер (3-че пункты карагыз).

Әгәр Сезгә язма чакыру килмәсә , яки Сезгә килгән язма чакыру тулы булмаса:

- Сорау алуны соңрак датага кичектерүне яки адвокатыгыз белән консультация өчен вакытны бер тапкыр гына сорый аласыз.
- Сезнең адвокатыгыз белән телефон аша сөйләшүне сайлау хокукыгыз бар, аннан соң сораштыру башланырга мөмкин.
- Сезнең адвокатыгызның килүен билгеле урындакөтү хокукыгыз бар.

D. Сорау алу дәвамында юридик ярдәм

Сезнең адвокатыгыз тәэмин итеп торачак:

- Сезнең тынлык саклау хокукын һәм сезнең үз-үзегезгә каршы таныклама бирмәү хокукын тәртиптә саклауны;
- сорау алу дәверендә Сезнең белән тиешле дәрәҗәдә әнгәмә кору, һәм шулай ук сезгә карата мәҗбүр итүләрне яки хокуксыз басым ясауны булдырмауны;
- Сезнең үзегезнең хокукларыгыз турында белүне, һәм шулай ук, сорау алу законлы рәвештә үткәрелүне.

Сезнең адвокатның бу сорау буенча нинди дә булса ачыкламалары булса, ул аларны шунда ук протоколга кертә ала. Сезнең адвокат төгәл запрос ясарга мөмкин яки төгәл кешедән сорау алуны таләп итергә мөмкин. Ул бирелгән сорауларга аңлатма бирелүне сорарга мөмкин. Ул тикшерүгә һәм сорау алуга карата ачыкламалар бирергә мөмкин. Аның Сезнең өчен җавап бирергә һәм сорау алуга каршы төшәргә хокукы юк.

E. Мин бу хокуктан баш тарта аламмы?

Сез адвокатыгыз белән яшерен консультация үткәрүдән баш тарта аласыз.

Сез бу хокуктан ирекле рәвештә һәм җитди уйланулардан соң баш тарта аласыз, әгәр:

- Сез балигъ яшькә җиткән булсагыз;
- бу очракка сезнең имзаланган һәм дата куелган документыгыз бар.

## 2. Фактлар турында кыскача мәгълүматлар

- Сезнең үзегездән сорау алыначак фактлар турында кыскача мәгълүмат алуга хокукыгыз бар.

## 3. Эндәшмәү хокукы

- Бернинди шартта да сез үзегезгә каршы таныклама бирергә тиеш түгел.
- Сезнең кемлегегезне билгеләгәннән соң сезнең белдерү ясарга яки сорауларга җавап бирергә яки тынлык сакларга хокукыгыз бар.

## 4. Сорау алу вакытындагы өстәмә хокуклар

Сорау алу күпмедер хәбәрләрдән башлана. Җинаять турындагы ахыргы хәбәрләргә һәм Сезнең тынычлык саклау мөмкинлеге булуы турында әйтеп узуга өстәп, Сезгә хәбәр итәчәкләр:

- Сез бөтен бирелгән сорауларның һәм Сез биргән җавапларның алар әйтелгән рәвештә теркәлеп баруларын таләп итә аласыз;
- Сез төгәл запрос ясарга мөмкин яки төгәл кешедән сорау алуны таләп итәргә мөмкин;

Сезнең белдерүләр тиешле дәлил итеп кулланыла алалар.

- Сез кул астында түгел һәм төрле вакытта төрле җиргә китә аласыз.
- Сорау алу дәверендә Сез үзегезнең карамакта булган төрле документлар куллана аласыз, бары Сез моны әшли алырсыз, сорау алу кичектерелмәгән булса гына. Сорау алу дәверендә яки ул узганнан соңСез бу документларны язма протоколга теркәлүне яки суд сәркәтибе белән тутыртылуларын сорый аласыз.

## 5. Сорау алу ахырында

Сорау алу тәмамланганнан соң Сезгә укыр өчен сорау алуның язмасын бирәчәкләр. Шулай ук Сез аны Сезнең өчен укуларын сората аласыз.

Сездән узегез ясаган белдерүләргә нинди дә булса үзгәртүләрне яки аңлатмаларны кертергә теләгегез булу турында сораячаклар.

## 6. Тәрҗемәче ярдәме һәм тәрҗемә итү хокукы

- Әгәр Сез суд процессы телендә сөйләшмисез яки аңламыйсыз яки Сезнең сөйләм яки ишетү кыенлыклары булса, Сезгә сорау алу дәверендә ярдәм күрсәтү өчен присягага китерелгән тәрҗемәче чакыртылачак. Бу ярдәм бушлай.
- Сезгә шулай ук үзегезнең белдерүләрне Сезнең туган телегездә язу мөмкинлеге бирелә ала.
- Әгәр Сез суд процессы телен аңламасагыз, Сез кулга алу ордерының, повестка, суд карарының өлешләрен Сез аңлаган телгә тәрҗемә ителуенә хокукыгыз бар. Бу ярдәм бушлай тәэмин ителә.

**Сезнең хокукларыгыз турындагы бу аңлатманы Сез саклый аласыз.**